**1. Оештыру-мотивлаштыру***(1 минут)*

- Хәерле көн, укучылар! Кәефләребезне күтәрү өчен әйдәгез әле бер беребезгә матур сүзләр әйтик. Без изге теләкләр теләсәк кояшыбыз да якты нурларын сибәр. Иптәшләрегезгә ягымлы сүз әйтегез дә алдыгыздагы нурны кояшка ябыштырыгыз. *Нурларны тактадагы түгәрәккә ябыштыралар, кояш барлыкка килә.*

**2. Актуальләштерү***(1 минут)*

- Укучылар, әлеге плакатка карап нинди җөмләләр төзи аласыз? (Татарстанда шәһәрләр күп. Рәсемдә флаг бар. Рәсемдә милли ашлар, киемнәр, уен кораллары сурәтләнгән) *җөмлә экранга чыга*

**3. УМК***(2 минут)*

- Дөрес, укучылар. Әйдәгез әле, шушы җөмләнең баш кисәкләрен табыйк. *(слайдларда күрсәтелә)*

- укучылар, игътибар итегез әле, бу җөмләнең нинди үзенчәлекле ягы бар? (бер үк төрле тикшерелгән кисәкләр бар)

- әйе, монда бер үк төрле тикшерелгән җөмлә кисәкләре бар. Әйтегез әле, аларның нинди уртак яклары бар? (Бер үк сорау куйдык, бер үк сүз төркеме белән белдерелгәннәр)

- Бер үк сорауга җавап биреп, бер үк җөмлә кисәге булган, бер үк сүз төркеме белән белдерелгән җөмлә кисәкләрен ничек атыйбыз, укучылар? (Тиңдәш кисәкләр)

- Тиңдәш сүзенең мәгънәсен аңлатмалы сүзлектән карыйк. ...., укы әле бу сүз нәрсә аңлата икән? (*сүзлек бн эш)*

- Димәк, ..., безнең бүгенге дәреснең темасы нинди була инде? (“Җөмләнең тиңдәш кисәкләре”)

- Без дәрестә бүген нәрсәләр эшләрбез соң? (Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен өйрәнербез, күнегүләр эшләрбез, тиңдәш кисәкләрне сөйләмдә кулланырга өйрәнербез)

-Нәтиҗәнең дөреслеген тикшерик. Дәреслек авторлары ни дигән? ..., 156нчы биттәге кагыйдәне укы әле.

- Хәзер теманы дәфтәрләргә язып куябыз.*(Экранда число, тема)* ә мин һәр төркемгә зур кояшыбызның бер өлешен бүләк итәм, анда дәресебезнең темасы язылган.

**4. УМЧ**

1. Фронталь эш *(1 минут)*

- Укучылар, экранга игътибар итегез әле. Әлеге җөмләләрне чагыштырып карагыз. Тиңдәш кисәкләрнең әһәмияте нәрсәдә? (тиңдәш кисәкләр күбрәк мәгълүмат бирәләр, җөмләләрне матурлыйлар)

- дөрес. Язучылар, шагырьләр дә әсәрләрен матурлау, тулыландыру өчен тиңдәш кисәкләр кулланалар. Укучылар, бу рәсем сезгә танышмы? Ул нинди экияттән? Әкиятнең авторы кем? (“Су анасы”, Г.Тукай)

- дөрес. Менә “Су анасы” экиятеннән өзек. Шушы җөмлләдән тиңдәш кисәкләрне табып карыйк әле. (койнам, йөзәм, чәчәрәтәм, уйныйм, чумам, сөзәм)

2. Төркемнәрдә эш *(1 минут)*

- күргәнебезчә, тиңдәш кисәкләр белән без балачактан ук таныш. Сезнең алда Габдулла Тукайның “Шүрәле” экиятеннән барыгыз да белә торган өзек язылган таҗ бар. Сезгә төркемнәрдә җөмләнең буш урыннарын тулыландырып язарга кирәк. Эшегезне төгәлләгәч таҗны түгәрәккә беркетеп куегыз.

- Җавапларыгызны тикшереп, үзбәя карточкаларыгызга билге куегыз.

3. Парларда эш *(1 минут)*

- Якташыбыз шагыйрь Хәмит Миңнегалиев та үз иҗатында тиңдәш кисәкләр кулланган. Сезнең алда Актанышыбызның гимнына әйләнгән “Актаныш туган ягым” шигыреннән өзек. Алдыгыздагы таҗга шушы

куплеттагы тиңдәш кисәкләрнең нинди җөмлә кисәге булып килүен язып алыгыз да түгәрәккә беркетегез. Бу эшне без парларда эшлибез.

- Җавапларыгызны тикшереп үзегезгә билге куегыз.

**ФИЗКУЛЬТМИНУТКА** *(1 минут)*

4. Дәреслек белән эш *(2 минут)*

- Укучылар дәреслектәге 302нче күнегүне эшлибез. Җөмләләрдән тиңдәш кисәкләрне генә язып алабыз. Күнегүне дәфтәрләрдә эшлибез.

- җавапларыгызны тикшереп, билгеләр куегыз.

5. Индивидуаль эш *(3 минут)*

- укучылар, игътибар итегез әле. Монда нәрсәләр күрсәтелгән?

- ничек уйлыйсыз ни өчен мин сезгә республикабызның гимнын тәкъдим иттем икән. <u>(Чөнки гимнда тиңдәш кисәкләр бар)</u>

- дөрес, хәзер алдыгыздагы тажга гимнда булган тиңдәш кисәкләрне язып алыгыз да, беркетеп куегыз. Җавапларыгызны тикшереп үзегезгә билге куегыз.

- күргәнебезчә, укучылар, тиңдәш кисәкләр телебезне матурлау, тулыландыру өчен әсәрләдә генә түгел, хәтта дәүләт мөһимлегендәге гимнда да кулланыла.

- үзегезне тикшереп карау өчен дәфтәрләрегездә әлеге тестны эшләгез *(экранда тест күрсәтелә)*

- иптәшегез белән алмашып җавапларыгызны тикшерегез.

- үзбәя карточкаларыгызда билгеләр куегыз.

- әйдәгез хәзер үзегез тиңдәш кисәкләр кулланып җөмләләр төзеп карагыз. <u>(Без дәрестә укыдык, яздык, сөйләдек. Бакчада кишер, суган, чөгендер үсә. Урманда кызыл, сары, зәңгәр күбәләкләр оча.)</u>

**5. Рефлексия** *(1 минут)*

- укучылар, дәрес башында матур сүзләр әйтеп кояшыбызны яктырткан идек. Нәтиҗәдә һәр төркемдә дә матур чәчәк барлыкка килде.

- Бүгенге дәрестә сез нәрсәләр белдегез?

- җөмләнең тиңдәш кисәкләре дип нәрсәләргә әйтәбез?

- нинди җөмлә кисәкләре тиңдәшләнеп килә ала?

- үзбәя карточкаларыгызга карап үзегезгә дәрескә билге куегыз.

- укучылар өй эшен язып алыгыз.

- Дәрес тәмам. Рәхмәт, укучылар. Сау булыгыз.